| СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯМБУЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

07.04.2025 с.Ямбулатово № 55 – 280

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2, 4, 7.2 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясындагы 25, 7 өлеше, «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан районының территориаль сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын тәкъдим итү турында» 2025 елның 27 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын һәм аның график сурәтен ун елга расларга (кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советының 2020 елның 4 мартындагы 67-288 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайтында (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Ямбулат авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы Югары Ослан районы, Крестников авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.А.Жестков

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының 07.04.2025 ел, № 55-280 карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасы

1 нче Крестниково бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-30

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Крестниково авылы,Үзәк ур., 6А-54йортлар (җөп як).

2 нче Крестниково бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-32

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Крестниково авылы, Үзәк ур., 45Б дан 59 га кадәр (так як), 56-78 йорт (җөп ягы), Нагорная ур., Киселевка ур., Заринская ур.

3 нче Крестниково бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-34

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Крестниково авылы, Үзәк ур., 7-45А йортлар (так як).

4 нче Крестниково бер мандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-34

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Крестниково авылы, Казан ур., Мәктәп урамы.

5 нче Ямбулат бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-30

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Крестниково авылы, Үзәк ур., 1 - 6, Ямбулат авылы,Коновалов ур., 1 - 43 (так ягы).

6 нчы Ямбулат бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-30

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше

түбәндәге чикләрдә керә: Ямбулат  авылы, Коновалов ур., 30-40 йорт (җөп ягы), 45-55 йорт (так ягы), Казыльяр авылы.

7 нче Ямбулат бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-30

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Ямбулат авылы, Коновалов ур., 2-28 (җөп як).

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советының 07.04.2025 ел № 55 — 280 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте



6
Сулица
2
Крестниково
3
1
4
5
Ямбулатово
6
7